КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 26 февраль г.Казань № 137

Татарстан Республикасы территориясендә башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары гамәлгә ашырыла торган, 2025 елда педагогик эшчәнлектәге казанышлар өчен Татарстан Республикасының иң яхшы укытучыларына премияләр бирү конкурсында җиңүче укытучылар эшли торган мәгариф оешмалары җитәкчеләренә 2026 елда бер тапкыр бирелә торган түләү турында

Татарстан Республикасындагы мәгариф лидерларына ярдәм күрсәтү, алдынгы идарә итү һәм педагогик тәҗрибәне тарату, белем бирү сыйфатын яхшырту һәм педагогик хезмәткәрләрнең хезмәт хакын арттыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы территориясендә башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары гамәлгә ашырыла торган, 2025 елда педагогик эшчәнлектәге казанышлар өчен Татарстан Республикасының иң яхшы укытучыларына премияләр бирү конкурсында җиңүче укытучылар эшли торган мәгариф оешмалары җитәкчеләренә 2026 елда 30,0 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган түләүне (алга таба – бер тапкыр бирелә торган түләү) гамәлгә куярга.

2. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

бер тапкыр бирелә торган түләү Татарстан Республикасы территориясендә башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары гамәлгә ашырыла торган, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Педагогик эшчәнлектәге казанышлар өчен Татарстан Республикасының иң яхшы укытучыларына премияләр бирү конкурсын үткәрү турында» 2018 ел, 28 март,

181 нче карары нигезендә үткәрелгән 2025 елда педагогик эшчәнлектәге казанышлар өчен Татарстан Республикасының иң яхшы укытучыларына премияләр бирү конкурсында укытучылары җиңүчеләр дип билгеләнгән һәм Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары гамәлгә ашырыла торган мәгариф оешмаларының педагогик эшчәнлектәге казанышлар өчен премияләр түләнә торган укытучылары исемлеген раслау турында» 2025 елның 31 июлендәге 561 номерлы боерыгы белән расланган башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары гамәлгә ашырыла торган мәгариф оешмаларының педагогик эшчәнлектәге казанышлар өчен премияләр түләнә торган укытучылары исемлегенә кертелгән мәгариф оешмалары җитәкчеләренә бирелә;

әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслау «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2025 елның 29 ноябрендәге 81-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында әлеге максатлар өчен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына 60 көн эчендә Татарстан Республикасы территориясендә башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары гамәлгә ашырыла торган, 2025 елда педагогик эшчәнлектәге казанышлар өчен Татарстан Республикасының иң яхшы укытучыларына премияләр бирү конкурсында җиңүче укытучылар эшли торган мәгариф оешмалары җитәкчеләренә 2026 елда бер тапкыр бирелә торган түләүне бирү тәртибен эшләргә һәм расларга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 елда педагогик эшчәнлектәге казанышлар өчен Татарстан Республикасының иң яхшы укытучыларына премияләр бирү конкурсында җиңүче укытучылар эшли торган Татарстан Республикасы территориясендә башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары җитәкчеләренә 2025 елда бер тапкыр бирелә торган түләү турында» 2025 ел, 30 май, 380 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин